РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» февраля 2022г. г. Альметьевск № 64

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 19 апрелендәге 98 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әләт шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Региональ законнар Аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын «Кодекс» мәгълүмат системасын куллану практикасы темасы буенча видеоконференция режимындагы киңәшмә беркетмәсенең 3 пунктына таянып, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2021 елның 27 декабрендәге 02-08-02/1370 номерлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 19 апрелендәге 98 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әләт шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында нигезләмә хакында»гы карарына (Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 11 маендагы 119 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«4.Территориаль иҗтимагый үзидарә аның Уставы нигезендә юридик зат була ала һәм коммерциячел булмаган оешманың оештыру-хокукый формасында дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.»;

13 статьяның 1 елешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) проект инициаторлары сыйфатында инициативалы проектны тәкъдим итә алалар.»;

- 14 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан

Зак. № 1352-200

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә (Шәйхетдинова Ф.А.) йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов